КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 июль г.Казань № 566

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы структурасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 1 ноябрь, 518 нче; 2005 ел, 6 декабрь, 574 нче; 2006 ел, 16 март, 103 нче; 2006 ел, 21 апрель, 201 нче; 2008 ел, 18 апрель, 239 нчы; 2008 ел, 22 декабрь, 911 нче; 2010 ел, 17 июнь, 482 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1034 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 30 сентябрь, 815 нче; 2012 ел, 10 август, 696 нчы; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2013 ел, 18 март, 173 нче; 2013 ел, 25 июль, 525 нче; 2014 ел, 6 март, 141 нче; 2014 ел, 13 август, 586 нчы, 2015 ел, 21 май, 363 нче, 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 6 июль, 487 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 747 нче; 2018 ел, 27 апрель, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи хезмәт хаклары буенча 1 341,033 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 58 берәмлек итеп билгеләргә.»;

4 нче һәм 5 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәне (락карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы структурасын расларга.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» турында 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында» 2005 ел, 1 ноябрь, 518 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына теркәлгән «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләре карамагына тапшырыла торган структур (территориаль) бүлекчәләренең штат саны» дигән кушымтага үзгәрешләр кертү хакында» 2005 ел, 6 декабрь, 574 нче;
«Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы;
«Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы структурасы турында» 2006 ел, 16 март, 103 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» турында 2005 ел, 18 август, 409 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2006 ел, 21 апрель, 201 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 18 апрель, 239 нчы;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» турында 2005 ел, 18 август, 409 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 22 декабрь, 911 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2010 ел, 17 июнь, 482 нче;
«Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт бюджет һәм казна учреждениеләре өчен заказлар урнаштыруны оештыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 10 декабрь, 1034 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары турындагы нигезләмәләргә

мобилизация әзерлеге буенча функцияләр кертү хакында» 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче карарының 1 нче пунктындагы утыз өченче – утыз бишенче абзацлар;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 30 сентябрь, 815 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 10 август, 696 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1098 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында» 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче карарының 1 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 18 март, 173 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигез-ләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 25 июль, 525 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2014 ел, 6 март, 141 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигез-ләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 13 август, 586 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре турында» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 21 май, 363 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карарының 4 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 6 июль, 487 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 30 сентябрь, 747 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 27 апрель, 301 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 июль, 566 нчы карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасында мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы тармак компетенциясендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы булып тора.

1.2. Министрлык үз компетенциясе белән билгеләнгән чикләрдә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмалар белән бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча хезмәттәшлек итә.

1.3. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, шулай ук бу Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.4. Министрлык юридик зат хокукларына ия, үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокукларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, бурычларны үтәргә, судларда дәгъвачы, җавап бирүче һәм өченче зат булырга, аның Татарстан Республикасының Дәүләт гербы төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере һәм бланкы, үз эшчәнлеге өчен кирәкле башка мөһерләре, штамплары, бланклары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә ачыла торган тиешле бюджет һәм башка счетлары булырга мөмкин.

1.5. Министрлык үз эшчәнлеге өчен кирәкле мөлкәт, матди-техник чаралар, җиһаз белән тәэмин ителә.

Министрлыкка Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә беркетелгән мөлкәт аның оператив идарәсендә була.

1.6. Министрлык эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча хисабына башкарыла.

1.7. Министрлыкның урнашу урыны: 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

Министрлыкның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга юнәлдерелгән республика дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнашу, Татарстан Республикасында гражданнарның иҗат ирегенә конституцион хокукларын тормышка ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру, мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалану, мәдәни кыйммәтләрдән һәркем файдалана алу.

2.2. Татарстан Республикасы халыкларына аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклап калуда һәм мәдәниятне үстерүдә, Россия Федерациясе субъектларында һәм чит илләрдә милли-мәдәни автономияләр һәм аларның территориаль органнары, башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итеп милләтара мәдәни элемтәләрне ныгытуда булышлык күрсәтү.

2.3. Мәдәният (шул исәптән һөнәри сәнгать, кинематография, фотография, музей һәм китапханә эше, декоратив-гамәли, монументаль сәнгать һәм халык иҗаты, мәдәни-танып белү туризмы, мәдәни мирас, мәдәният тармагында мәгариф һәм фән) өлкәсендә эшчәнлекнең аерым төрләрен үстерү максатларын һәм өстенлекләрен билгеләү.

2.4. Муниципаль берәмлекләргә ял итү өлкәсен үстерүдә, халыкның төрле катламнарының мәдәни-ял эшчәнлеген төрлеләндерүне тәэмин итүдә булышлык күрсәтү.

2.5. Татарстан Республикасы мәдәниятенең дөньякүләм мәдәни киңлеккә интеграцияләү процессын тәэмин итү.

## 3. Министрлыкның функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16)*;

мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндәге дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга булышлык күрсәтү (04.03), шул исәптән:

Татарстан Республикасы милкендәге китапханәләр белән халыкка хезмәт күрсәтү белән идарә итү (04.03.01);

---

* Кодны билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

музейларга, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә, халык сәнгать кәсепләренә (Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган искәрмәләрдән тыш), республика һәм җирле милли-мәдәни автономияләргә ярдәм күрсәтү, мәгариф учреждениеләрендә милли телләрне һәм этномәдәни юнәлештәге башка предметларны, кинематографияне өйрәнү, шулай ук төрле диндәге дини берләшмәләрне үстерүгә булышлык күрсәтү һәм алар арасында үзара аңлашуны ныгытуга булышлык күрсәтү (04.03.02).

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01);

Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү (01.02.1);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3);

Татарстан Республикасының Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

якын һәм ерак чит илләр белән икътисадый, мәгълүмати һәм мәдәни элемтәләрдә, шул исәптән ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә ярдәм күрсәтү (01.03.2);

энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14);

ваклап сату базарларын оештыруга, ваклап сату базарларында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (03.05.03);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (03.07);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территорияне планировкалау буенча документлар әзерләүне тәэмин итү (01.05.02);

шәһәр төзелешен проектлауның төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.03);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәт (бина, корылма),

транспорт, җиһаз, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07.01);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – хезмәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларда балаларга өстәмә белем бирү эшчәнлеге белән идарә итү (04.05.01.4);

урта һөнәри белем бирү белән (федераль белем бирү оешмаларында алына торган белемнән тыш) билгеләнгән тәртиптә идарә итү (04.05.06);

өстәмә һөнәри белем бирү белән (федераль белем бирү оешмаларында алына торган белемнән тыш) билгеләнгән тәртиптә идарә итү (04.05.08);

Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләрен (физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме буенча белем бирү программаларын, сәнгатьләр өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләреннән тыш) аттестацияләү (04.05.09);

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндәге дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга булышлык күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03);

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән.

3.3. Министрлык бу Нигезләмәнең 3.1 нче һәм 3.2 нче пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.3.1. Татарстан Республикасы территориясендә мәдәният өлкәсен үстерү тенденцияләренә комплекслы анализ үткәрә һәм фараз бирә, мәдәни эшчәнлекнең аерым төрләрен үстерүнең максатларын һәм өстенлекләрен нигезли;

3.3.2. Татарстан Республикасының мәдәниятен үстерү буенча дәүләт программаларын, өстенлекле юнәлешләрне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча хөкүмәт карарларын эшләүдә катнаша;

3.3.3. Дәүләт программаларын эшләүдә һәм тормышка ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

3.3.4. Тармакка дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыра, шул исәптән тарихи-мәдәни кыйммәткә һәм музей әһәмиятенә ия булган предметларны, халык сәнгать кәсепләре эшләнмәләрен, сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләрен, кинематография әсәрләрен (заказчының аудиовизуаль әсәрләр ясау, шулай ук киновидеопрокат шартнамәләрен төзү буенча вәкаләтләрен кертеп), фотографияләр, дәүләт музей, китапханә һәм башка шундый фондларны, театрлар һәм музыка коллективлары репертуарларын тулыландыру максатларында драматургия һәм музыкаль әсәрләр сатып ала, шулай ук тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган акча чикләрендә әлеге әсәрләрне иҗат итү эшләрен финанслауны гамәлгә ашыра;

3.3.5. Дәүләт социаль стандартлары, дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү кысаларында халыкка мәдәният хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт заказын формалаштыруда катнаша, федераль законнар нигезендә товарлар сатып алуны, эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне (шул исәптән сәнгать әсәрләре иҗат итүгә һәм сатып алуга) гамәлгә ашыра;

3.3.6. Муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын, Татарстан Республикасының иҗтимагый инфраструктура объектларын төзү программасын финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә субсидияләргә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт оешмаларының төп чараларына капиталь кертемнәргә булган гомуми ихтыяҗны формалаштыруда, шул исәптән җирле үзидарә органнары гаризалары нигезендә катнаша.

3.3.7. Министрлык карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының һәм оештыру максатларына ирешү өчен башка оешмаларның коммерциячел проектларын һәм башка эшмәкәрлек башлангычларын тормышка ашыруга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра;

3.3.8. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт заказы составында билгеләнә торган вәкаләтләрне үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары мәгънәләренә ирешүне тәэмин итә;

3.3.9. Мәдәният өлкәсендә икътисадый үзгәрешләр юнәлешләрен эшли;

3.3.10. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештереп, мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга һәм үстерүгә бүлеп бирелгән бюджет һәм бюджеттан тыш акчасын бүлә, аларны нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

3.3.11. Министрлык карамагындагы дәүләт оешмаларын финанслауны тәэмин итә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра, муниципаль берәмлекләргә китапханә челтәрен һәм мәдәни-ял оешмалары челтәрен булдыруда булышлык күрсәтә;

3.3.12. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә дәүләт-шәхси партнерлыкны үстерүгә булышлык күрсәтә;

3.3.13. һөнәри сәнгатьнең барлык төрләрен һәм жанрларын үстерүгә, татар һәм дөньякүләм мәдәниятенең бик танылган эшлеклеләренең иҗади мирасын саклап калуга булышлык күрсәтә;

3.3.14. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә театр-тамаша оешмаларын төзи, үстерә һәм аларга ярдәм күрсәтә, авторлык һәм катнаш хокукларны яклауда булышлык күрсәтә;

3.3.15. Талантлы яшьләргә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләренә адреслы ярдәм күрсәтү механизмнарын формалаштыра;

3.3.16. Татарстан Республикасында һәм аннан читтә гастрольләр һәм күргәзмә эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне, иҗат коллективлары, мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары, мәдәният, сәнгать һәм кинематография буенча мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар багланышларын һәм элемтәләрен төбәкара дәрәҗәдә булдыруны һәм үстерүне гамәлгә ашыра;

3.3.17. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә фәнни һәм гамәли тикшеренүләр юнәлешләрен билгели һәм аларны үткәрү эшен яраштыра;

3.3.18. Татарстан Республикасының китапханә эшен, халык иҗатын, мәдәни-ял өлкәсен үстерү максатларын һәм өстенлекләрен билгели;

3.3.19. Татарстан Республикасында фотосәнгатьне үстерүгә булышлык күрсәтә;

3.3.20. Татарстан Республикасы исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган шәхси хокукларны һәм бурычларны, шулай ук Россия Федерациясенең Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә карата дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыра;

3.3.21. Татарстан Республикасы дәүләт музейларын оештыру һәм аларга ярдәм күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

3.3.22. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт керемен әйләндерелгән мәдәни кыйммәтләрне Россия Федерациясенең дәүләт музей, архив һәм китапханә фондларына тапшыруны гамәлгә ашыра;

3.3.23. Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей коллекцияләренең дәүләт каталогын алып бара;

3.3.24. Татарстан Республикасы музейлары реестрын алып бара;

3.3.25. Халык иҗатын саклап калуга һәм үстерүгә, халыкның мәдәни-ял итү эшчәнлеге төрлелеген тәэмин итүгә булышлык күрсәтә;

3.3.26. Халык сәнгать кәсепләрен үстерү буенча программа чараларын эшли һәм тормышка ашыра;

3.3.27. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының иҗат берлекләре, милли-мәдәни автономияләр һәм җәмгыятьләр белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

3.3.28. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли мәдәниятен үстерүгә булышлык күрсәтә;

3.3.29. Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча милли-мәдәни автономияләргә, иҗади берлекләргә, башка иҗтимагый оешмаларга методик, оештыру һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтә;

3.3.30. Мәдәни хезмәттәшлеккә нигезләнгән милләтара һәм төбәкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне, шулай ук Министрлыкка бирелгән вәкаләтләр чикләрендә төрле халыкара оешмалар белән үзара хезмәттәшлеккә таянып, Татарстан Республикасын дөньякүләм мәдәниятенә интеграцияләүне гамәлгә ашыра;

3.3.31. Мәдәният-танып белү туризмын үстерүгә булышлык күрсәтә;

3.3.32. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга сала торган закон һәм башка норматив хокук актларын (шул исәптән хезмәт өчен түләү өлешендә) тормышка ашыруны тәэмин итә;

3.3.33. Бирелгән вәкаләтләр чикләрендә мәдәният белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләрен аттестацияләүне гамәлгә ашыра;

3.3.34. Татарстан Республикасы карамагындагы мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары хезмәткәрләрен аттестацияләүне гамәлгә ашыра;

3.3.35. Мәдәният өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүнең комплекслы программаларын эшли һәм тормышка ашыра, кадрлар әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыра;

3.3.36. Тармак хезмәткәрләренә һәм мәдәният эшлеклеләренә социаль ярдәм күрсәтү һәм хокукый яклау чараларын гамәлгә ашыра, аларны дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамә бирә;

3.3.37. Мәдәният өлкәсендә өзлексез белем бирүне үстерүнең һәм, тармактагы хезмәт базары ихтыяҗларыннан чыгып, мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары өчен тармакны кадрлар белән тәэмин итүнең төп юнәлешләрен билгели;

3.3.38. Монументаль сәнгать (һәйкәлләр, монументлар, бюстлар, мемориаль такталар, скульптура-архитектура ансамбльләре һәм башкалар) әсәрләрен проектлаштыру, иҗат итү һәм кабул итү эшчәнлеген оештыра;

3.3.39. Татарстан Республикасы торак пунктлары урамнарына, мәйданнарына һәм башка состав өлешләренә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, фән һәм сәнгать вәкилләре һәм дәүләт алдында казанышлары булган башка затлар исемнәрен бирү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;

3.3.40. Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты карарлары һәм министрлыклар һәм ведомстволар тарафыннан кертелә торган башка норматив хокук актлары проектлары буенча бәяләмәләр әзерли;

3.3.41. Үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын, чит илләрдә яшәүче ватандашларга карата дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнаша;

3.3.42. Мәгълүмати ярдәм, шулай ук мәдәният учреждениеләренә, җирле үзидарә органнарына, иҗат хезмәткәрләренә, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә законнарны куллану мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтә;

3.3.43. Министрлыкның, эшчәнлеге Министрлык эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагындагы өлкәдә булган оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук бу чараларны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

3.3.44. Министрлык компетенциясе чикләрендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән гавами-хокукый характердагы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар реестрын алып бара;

3.3.45. Ел саен, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча вәкаләтле органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап кертә;

3.3.46. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү, аларны бетерү турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесенә дәүләт учреждениесе уставында каралган эшчәнлекнең төп төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшли;

ел саен ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәвен бәяли;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килү-килмәвен бәяли;

3.3.47. Үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында законнар һәм хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра;

3.3.48. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарга үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

3.3.49. Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый;

3.3.50. Тармакны кадрлар белән тәэмин итү торышына мониторингны гамәлгә ашыра;

3.3.51. Тармакның урта һөнәри белем бирү, югары белем бирү белгечлекләре һәм һөнәрләре буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә ихтыяҗын фаразлауны булдыруны оештыра;

3.3.52. Татарстан Республикасының фәнни-белем бирү кластерларында белгечләр әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә дәүләт заказына тәкъдимнәр булдыра;

3.3.53. Мәдәният өлкәсендә хезмәт ресурсларын җәлеп итү һәм аларны эш белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

3.3.54. Гражданлык бердәмлеген, милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күпкырлылыгын саклауга, милли азчылыкның хокукларын яклауга, милләтара (этникара) каршылыкларны профилактикалауга һәм милләтара һәм конфессияара килешүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыра;

3.3.55. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасы кысаларында, мәгълүмат җыюны, саклауны, эшкәртүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

3.3.56. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасы эшен фәнни-методик яктан тәэмин итү мәсьәләләре буенча «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

3.3.57. Россия Федерациясендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм анализлауны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән үзара хезмәттәшлек функцияләрен башкара;

3.3.58. Үз компетенциясе чикләрендә экстремизм эшчәнлегенә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итә;

3.3.59. Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя бирүне оештыру өчен федераль законнар нигезендә шартлар тудыра;

3.3.60. Иҗтимагый оешмалар катнашында Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя

бирүне үткәрү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның турындагы нигезләмәне раслый;

3.3.61. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турындагы мәгълүмат урнаштырыла торган рәсми сайтта урнаштыра;

3.3.62. Үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турындагы фикерләрен белдерүгә техник мөмкинлек тәэмин итә;

3.3.63. Юридик затларның документларын карый һәм мәдәният, сәнгать, кинематография объектларының, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә масштаблы инвестиция проектларының Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясында күрсәтелгән критерийларга, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган мондый критерийларның микъдари һәм (яки) күләм күрсәткечләренә туры килүе турындагы бәяләмәләр проектларын килештерә;

3.3.64. Үз эшчәнлеген җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра, аларның үтенече буенча аларга эшчәнлеген гамәлгә ашыруда кирәкле ярдәм күрсәтә, җирле үзидарә органнары белән муниципаль үсеш фондыннан, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә социаль чыгымнарны финанслашуның төбәк фондыннан субсидияләрнең җирле бюджетлар тарафыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары турында килешүләр әзерләүне, төзүне тәэмин итә;

3.3.65. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы карамагындагы, сәнгатьләр өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль һәм шәхси оешмаларның педагог хезмәткәрләренең квалификация категориясен билгеләү максатларында аттестация комиссиясен төзи;

3.3.66. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау, өйрәнү, популярлаштыру һәм алардан файдалану эшчәнлеген тәэмин итә һәм яраштыра;

3.3.67. Матди булмаган мәдәни мирас объектларының торышын мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

3.3.68. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын ачыклау, саклау, өйрәнү, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау буенча чаралар күрә;

3.3.69. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларны ачыклауга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр оештыруны, көнкүреш формаларын карауны һәм аларның торышын бәяләүне гамәлгә ашыра;

3.3.70. Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестрын алып баруны гамәлгә ашыра һәм матди булмаган мирас объекты билгеләренә ия булган объектларны Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестрына кертү яки кертүдән баш тарту турында карарлар кабул итә.

## 4. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кушуы буенча мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәнфәгатьләрен федераль башкарма хакимият органнарында якларга, үз вәкилләренең киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашуын тәэмин итәргә;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Россия Федерациясе субъектларының һәм чит ил дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары, халыкара оешмалар белән мәдәни хезмәттәшлек итү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзергә;

үз компетенциясе чикләрендә боерыклар рәвешендә норматив хокук актлары бастырып чыгарырга, Министрлык карамагындагы оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш булган кагыйдәләрне, нигезләмәләрне, регламентларны, инструкцияләрне, методик документларны расларга;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары, дәүләт программалары белән билгеләнә торган юнәлешләр буенча законнар белән күздә тотылган тәртиптә бүләргә;

бүлеп бирелә торган акча чикләрендә грантлар, стипендияләрне гамәлгә куярга;

Татарстан Республикасы мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә оешмаларга оператив идарәгә тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исәпкә алуны, саклауны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

мәдәният өлкәсендә яраштыру, консультация бирү органнары, иҗтимагый советлар, эксперт төркемнәре, вакытлыча иҗат коллективлары һәм башка шундый структуралар оештырырга һәм аларның эшендә катнашырга;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешләрендәге мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларыннан аларның функцияләрен үтәүгә бәйле документларны, шулай ук Министрлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мәгълүматларны сорарга һәм алырга;

мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләрен дәүләт бүләкләренә, премияләргә тәкъдим итү, теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге театрларга һәм сәнгать коллективларына – «академик» исемен, ведомство буйсынуындагы оешмаларга – күренекле тарих, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләре исемнәрен бирү турында үтенечнамә бирергә, «халык үзешчән коллективы» исемен бирергә;

норматив хокук актлары проектларын, методик документларны эшләү өчен, шулай ук Министрлык компетенциясенә керә торган аерым мәсьәләләрне хәл итү өчен фәнни һәм башка оешмаларны шартнамә нигезендә җәлеп итәргә;

мәдәният өлкәсендә конкурслар, фестивальләр, күргәзмәләр, күргәзмә-сатулар, симпозиумнар, конференцияләр, семинарлар, концертлар, китапханә алмашуы һәм башка чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

үз юнәлеше (буклетлар, журналлар, газеталар, методик әсбаплар, ноталар, билетлар, китаплар, афишалар һ. б.) буенча нәшрият эшчәнлеген оештырырга;

ведомство буйсынуындагы дәүләт бюджет, автоном һәм казна учреждениеләре – заказчылар өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен заказны үзәкләштереп урнаштыруны оештыру мәсьәләләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен сатып алына торган товарларның, башкарыла торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге буенча товарлар сатып алудан, эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән тыш) функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып торырга.

4.2. Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә карата дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда Министрлык вәкаләтләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән регламентлаштырыла.

## 5. Министрлык эшчәнлеген оештыру

5.1. Министрлыкны Татарстан Республикасы Президенты белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган министр җитәкли.

Министрның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан министр тәкъдиме буенча вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган урынбасарлары була.

5.2. Министр:

Министрлык эшчәнлеге белән шәхси идарә нигезендә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен шәхси җавап бирә;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын әзерләүдә катнаша, аларның үтәлешен тәэмин итә;

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы, бу Нигезләмә, Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән Министрлык җитәкчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Министрлык хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларга карата кызыксындыру чараларын куллана, законнар нигезендә дисциплинар һәм башка җаваплылыкка тарта;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре җитәкчеләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, шулай ук алар белән хезмәт шартнамәләре төзи, аларга үзгәреш кертә һәм аларны өзә;

Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрне раслый, министр урынбасарлары арасында йөкләмәләрне бүлә;

үз компетенциясе чикләрендә боерыклар рәвешендә норматив хокук актлары чыгара, кагыйдәләр, тәгъдимнамәләр, нигезләмәләр раслый, аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыра;

билгеләнгән хезмәткәрләр саны, хезмәт өчен түләү фонды һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә штат расписаниясен, Министрлыкны тотуга чыгымнар сметасын раслый;

Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген боерык белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә бәяләүне гамәлгә ашыра.

5.3. Министрлыкта аның киңәшмә органы булып торган һәм Министрлыкка йөкләнгән бурычлардан чыгып үз эшен башкара торган коллегия төзелә.

Коллегия составына министр, аның вазыйфа буенча урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография буенча республика төп оешмалары җитәкчеләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары җитәкчеләре, оешма җитәкчеләре, иҗат әһелләре, республика галимнәре керә.

Коллегия составы һәм аның саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Коллегия рәисе булып министр тора.

Коллегия утырышында мәсьәләләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә.

5.4. Мәдәният үсешенең төп юнәлешләре, мәдәният өлкәсендә бердәм фәнни алымнарны билгеләү, мәдәният өлкәсендә фән һәм техниканың, алдынгы тәҗрибәнең иң мөһим казанышларын кулланышка кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен Министрлык каршында яраштыру органы (совет) (аның составына галимнәрне, югары квалификацияле белгечләрне, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләрен, иҗат берлекләре, милли-мәдәни автономияләр, җәмгыятьләр һәм башка оешмалар вәкилләрен кертеп) оештырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының
Мәдәният министрлыгы
турындагы нигезләмәгә
кушымта


**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы**
**оешмалар белән хезмәттәшлек итә торган**
**икътисадый эшчәнлек төрләре**
**исемлеге**

| Икъти-садый эшчәнлек төрләре кодлары* | Икътисадый эшчәнлек төрләре исеме |
|---|---|
| 59 | Кинофильмнар чыгару, кинофильмнарны прокатка бирү |
| 59.1 | Фильмнар күрсәтү |
| 90.01 | Башкару сәнгатьләре өлкәсендә эшчәнлек (театр, опера һәм балет тамашаларын, концертлар һәм башка сәхнә чыгышларын оештыру һәм кую) |
| 90.03 | Индивидуаль эшләүче скульпторлар, рәссамнар, рәссам-мультипликаторлар, граверчылар, офортчылар эшчәнлеге |
| 90.04 | Концерт, театр заллары һәм башка мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге |
| 93.29 | Ял һәм күңел ачу өлкәсендә башка төркемнәргә кертелмәгән эшчәнлек (күңел ачу паркларыннан һәм аттракционлы парклардан тыш) |
| 90.01 | Ансамбльләр, цирк һәм театр труппалары, оркестрлар һәм музыкаль төркемнәр эшчәнлеге |
| 93.29.2 | Бию мәйданчыклары, дискотекалар, бию мәктәпләре эшчәнлеге |
| 93.29.3 | Башка төркемнәргә кертелмәгән бүтән тамаша-күңел ачу эшчәнлеге |
| 63.9 | Китапханәләр һәм архивлар эшчәнлеге |
| 84.12 | Дәүләт музейлары һәм мәдәниятнең башка учреждениеләре эшчәнлеге |
| 93.2 | Ял һәм күңел ачу өлкәсендә эшчәнлек |
| 85.41 | Балаларга өстәмә белем бирү |
| 85.42 | Һөнәри өстәмә белем бирү |
| 85.42.9 | Башка төркемнәргә кертелмәгән өстәмә һөнәри белем бирү эшчәнлеге (белгечләр әзерләү, аларны яңадан әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү) |
| 91.04 | Ботаника бакчалары, зоопарклар, дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар эшчәнлеге |

* Икътисадый эшчәнлек төрләре кодлары Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының (Росстандарт) 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст номерлы боерыгы белән расланган ОК 029-2014 Икътисадый эшчәнлек төрләре кодлары (КДЕС 2 нче ред.) нигезендә билгеләнә

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 12 июль, 566 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы
**структурасы**




______________________________